СОВЕТ ПЕЧИЩИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ПЕЧИЩИ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ КАРАР

07.09.2018 с. Печищи № 38-181

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советы карары, «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә гавами тыңлауларны оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 сентябрендәге 24-117 номерлы карары нигезендә, авыл җирлегендә яшәүчеләрнең ачык тыңлаулар уздыру юлы белән фикер алышуда катнашу хокукларын үтәү максатларында,

Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проектын 1 нче кушымта нигезендә кабул итәргә һәм аны гавами тыңлауларга чыгарырга.

2. Расларга:

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе 2 нче кушымта нигезендә;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» карары проекты буенча гавами тыңлаулар үткәрү тәртибе 3 нче кушымта нигезендә.

3. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеген төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында” карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2018 елның 12 октябрендә 10.00 сәгатьтә җирлекнең башкарма комитеты бинасында, Печищи авылы, Декабристлар урамы, 35а йорт адресы буенча уздырырга. .

4. Башкарма комитетка Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлегендә яшәүчеләрнең кергән тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районының Печищи авыл җирлеге Советы каравына кертергә.

5. 2018 елның 10 сентябренә кадәр әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), Печищи авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Совет Рәисе урынбасары,
Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Печищи авыл җирлеге башлыгы урынбасары Т. С. Нуруллин